КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 23 декабрь

г.Казань

№ 1400

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Безнең ишегалды» республика программасын әзерләү, формалаштыру һәм тормышка ашыру буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау хакында» 2019 ел, 23 ноябрь, 1071 нче карары белән расланган «Безнең ишегалды» республика программасын әзерләү, формалаштыру һәм тормышка ашыру буенча ведомствоара эшче төркем составына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Безнең ишегалды» республика программасын әзерләү, формалаштыру һәм тормышка ашыру буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау хакында» 2019 ел, 23 ноябрь, 1071 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 20 декабрь, 1170 нче, 2020 ел, 28 гыйнвар, 45 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Безнең ишегалды» республика программасын әзерләү, формалаштыру һәм тормышка ашыру буенча ведомствоара эшче төркем составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

ведомствоара эшче төркем составыннан Д.В.Анисимовны, А.Б.Гревцовны, А.Р.Кашаповны, И.Н.Насыйровны, Ф.Ф.Салиховны, Р.М.Шакировны, А.А.Ярмиевны чыгарырга;

ведомствоара эшче төркем составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Камаев Радик Рафаил улын | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы идарәсенең юл һәм төзелеш комплексларында инвестиция программаларын гамәлгә ашыру бүлегенең баш киңәшчесен |
| Мортазина Альбина Фәрит кызын | «Татарстан Республикасы Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе директоры урынбасарын |
| Петрова Арина Сергеевнаны | «Татарстан Республикасы шәһәрләрен үстрү институты» Фондының Стратегик проектлар белән идарә итү департаменты җитәкчесен (килешү буенча) |
| Фролов Алексей Михайловичны | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасарын. |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин